ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 19 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 3, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 86 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2025, № 75 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $10^1$ пункт өстәргә:
«$10^1$) Федераль законның 69 статьясындагы $3^3$ өлешендә күрсәтелгән затларны эшкә урнаштыру өчен шартлар тудыру, шул исәптән үз вәкаләтләре чикләрендә әлеге затларга өстәмә социаль ярдәм чаралары билгеләү;»;

2) 5 статьяда:
а) түбәндәге эчтәлекле $4^3$ пункт өстәргә:
«$4^3$) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары буйсынуындагы илкүләм медицина тикшеренүләр үзәкләре эшчәнлеген оештыру;»;
б) $16^5$ пунктта «тәртибен» сүзеннән соң «Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 13 пунктында каралган методик күрсәтмәләр нигезендә» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге статьяда үз көченә керүнең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, 2026 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының «б» пунктчасы 2026 елның 30 мартыннан үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының «а» пунктчасы 2026 елның 1 апреленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2026 ел, 21 февраль
№ 10-ТРЗ